КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1515

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү максатларында бирелгән кредит шартнамәләренә, заем шартнамәләренә, финанс арендасы (лизинг), банк гарантиясе бирү турындагы шартнамәләргә һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан төзелгән башка шартнамәләргә нигезләнгән йөкләмәләрне үтәүгә «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасының чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 483 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү максатларында бирелгән кредит шартнамәләренә, заем шартнамәләренә, финанс арендасы (лизинг), банк гарантиясе бирү турындагы шартнамәләргә һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан төзелгән башка шартнамәләргә нигезләнгән йөкләмәләрне үтәүгә »Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасының чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июнь, 483 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 18 август,

746 нчы, 2022 ел, 04 февраль, 83 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм аның инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 - 2025 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының «Төбәк гарантия оешмалары тарафыннан йөкләмәләр (гарантияләр) буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектларының йөкләмәләрен үтәү» чарасын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү максатларында бирелгән кредит шартнамәләренә, заем шартнамәләренә, финанс арендасы (лизинг), банк гарантиясе бирү турындагы шартнамәләргә һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан төзелгән башка шартнамәләргә нигезләнгән йөкләмәләрне үтәүгә «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасының чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2018 - 2025 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасында каралган «Кече һәм урта эшкуарлык һәм индивидуаль эшкуарлык инициативасына ярдәм» илкүләм проектының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары акселерациясе» федераль проектының максатына, күрсәткеченә һәм нәтиҗәсенә ирешүне тәэмин итә торган «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары Акселерациясе» төбәк проекты кысаларында «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү максатларында бирелгән йөкләмәләрне үтәү» чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба - Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак бирелә.

1.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча,

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.8 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант операторының, грант операторы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант операторының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

2.9 пунктта «2,959 млрд.сум» сүзләрен «килешүдә билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Министрлык Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

2.17 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин